

# ТУГАН ЯК
# РОДНОЙ КРАЙ

ГАЗЕТА СЕВЕРО-ЗАПАДА ОРЕНБУРГСКОЙ ОБЛАСТИ № 1 (16) 12 ЯНВАРЯ 2010

НОВОСТИ ТАТАРСКОГО МИРА

**ТР Президенты М.Ш. ШӘЙМИЕВНЕҢ Русия төбәкләрендә, БДБ һәм ерак чит илләрдә яшәүче милләттәшләребезгә**

## ЯҢА ЕЛ КОТЛАВЫ



**Хөрмәтле милләттәшләр! Сезне чын күңелдән Яңа 2010 ел белән тәбрик итәм.**

Төгәлләнеп килүче елны ирешелгәннәргә йомгак ясап озату күркәм гадәткә әйләнде, Мәгълүм кыенлыкларга да карамастан, икътисадта, социаль өлкәдә күп эшләр башкара алдык. Татарстан чит илләрдә яшәүче милләттәшләребезгә ярдәм итүгә кагылышлы бер генә проектны да туктатмады. Тәкъдимнәребезнең теләктәшлек уятуы, үзегезнең дә яңа эшләрдә башлап йөрүегез гаять куанычлы. Фикер-омтылышларыгыз безгә Бөтендөнья татар конгрессы, Татарстан вәкиллекләре, интернет-коммуникацияләр аша килеп ирешә. Мәскәүдә дөньяның барлык кыйтгаларыннан йөзләрчә кешене җыйган Милләттәшләрнең өченче Бөтендөнья конгрессы, ноябрь аенда Казанда узган Милләттәшләр форумы, түгәрәк өстәлләр, фәнни конференцияләр һәм башка очрашулар уртак эшебезне алга җибәрә. Туган телебезне саклау, рухи һәм әхлакый мирасыбызны тагын да баету максатында куйган тырышлыгыгыз өчен сезгә ихлас рәхмәт хисләремне җиткерәм. Глобальләшү шартларында төрле икътисадый һәм мәдәни бәйләнешләр үз рәвешен бик тиз үзгәртә. Халкыбызның төрле милләт вәкилләре һәм төрле дин тотучылар белән тату яшәү тәҗрибәсенә ихтыяҗ бүген аеруча зур. Тынычлык сөюче һәм мәгърифәтле татар халкы киләчәктә дә ышанычлылык һәм толерантлык үрнәге булып торыр, игелекле эшләрдә зур мөмкинлекләрен күрсәтер, дип ышанам. Яңа чор безгә зур бурычлар йөкли. Илебезне заманча үзгәртеп кору мәсьәләләрендә сезнең ярдәмегезгә дә исәп тотабыз. Безгә сез туплаган акыл һәм һөнәри осталык, үзегез яшәгән ил тәҗрибәсен исәпкә алган фикер һәм тәкъдимнәр кирәк. Уртак тарихи Ватаныбызны көчле һәм чәчәк атучы ил итәргә телибез һәм шушы максатка ирешү өчен көчләребезне берләштерәбез. Без Бөек Җиңүнең 65 еллык юбилее елында данлыклы ветераннарыбыз илдәге уңай үзгәрешләрне күреп сөенсен, күңел җылысы һәм кайгыртучанлык тоеп яшәсен өчен барысын да эшләргә тырышабыз. Безнең киләчәгебез һәрбер кешенең иҗтиһатына, шәхси инициативасына һәм гомуми эш нәтиҗәләре белән кызыксынуына бәйле. Барыгыз өчен дә 2010 ел иҗади уңышлар, үсеш һәм зур казанышлар елы булсын. Сезгә һәм гаиләләрегезгә исәнлек-саулык, иминлек һәм ак бәхетләр телим.

* * *

В «старый» новый год, 13 января, отмечается День российской печати. Это праздник не только официальных изданий, но и журналистов, работающих в редакциях газет издаваемых общественными организациями и частными лицами. В том числе и нашей газеты. Поздравляем читателей и наших внештатных помощников с праздником! Всем вам творческих успехов!

РЕПОРТАЖ

## ЗНАКОВОЕ НОВОСЕЛЬЕ У СЕЛЬЧАН




Где-то недалеко от Африки, есть небольшая татарская деревня Нижненовокутлумбетьево. Нет, я не оговорился про Африку. В Матвеевском районе есть села и поселки с такими чудными названиями: Африка, Роза, Сарай Гир. А вот деревню Нижненовокутлумбетьево местные жители называют Тулубаево. Ну, как бы не назвали, народ здесь живет работящий. Пьют отменную родниковую воду, которую можно заливать даже в аккумулятор, и не совершают преступлений. С правонарушителями здесь разговор короткий: или веди себя правильно, или вон из села. Говорят, есть среди известных российских ученых, общественных деятелей выходцы и из Тулубаево.

Ну а накануне Нового года здесь произошло знаковое событие. Дело в том, что этот населенный пункт попал в число «невезучих». Затеяли здесь еще в прошлом веке строительство школы и Дома культуры. Строительство было задумано масштабное, но поменялись времена. В результате были возведены лишь стены и перекрытия. Они, как немой укор , «смотрят» сейчас пустыми глазницами окон. Сельчане пригорюнились: не видать им нынче новоселья.



Еще во время предвыборной кампании, это «безобразие» увидел депутат Законодательного собрания Оренбургской области Ильдус Давлятов. Тогда он пообещал тулубаевцам, что очаг культуры у них будет. По правде говоря, сельчане отнеслись к этому скептически: мол, мало ли что наобещают во время выборов. Но Ильдус Ядкарович данное слово сдержал. На депутатские средства был проведен капитальный ремонт одного из заброшенных зданий. Практически пришлось все начинать с нуля. В результате сельчане получили прекрасный сельский Дом культуры.

По этому случаю было организовано его торжественное открытие, на которое пригласили «виновников» этого события: депутата И. Давлятова, главу Матвеевского районной администрации Э. Муфазалова и других. Надо отметить, что и районная и сельская администрации тоже внесли свой вклад в «очаг культуры». И Ильдус Ядкарович, и Эдуард Фатыхович выразили надежду, что деревня сохранит свое существование и в новом веке. Само же Тулубаево, по утверждению аксакалов, разменяло уже пятую сотню лет.

Сельчане поблагодарили их за солидный новогодний подарок. Ну а местные артисты, совместно с самодеятельностью соседнего села, дали замечательный концерт.



**На снимке:** во время торжества.

В ДНИ ПРАЗДНИКА

# РАДУЮТ МОЛОДЫЕ ТАЛАНТЫ



Несмотря на морозный январский вечер, в Асекеевском районном Доме культуры, как говорится, некуда было яблоку упасть. Здесь, 8 января, силами местных артистов был дан концерт «Яна ел туре». Несомненно, звездой концерта стала Виолетта Валишина. Она лауреат многочисленных солидных конкурсов, представляла наш район и нашу область во многих состязаниях талантов. Когда бывает в Асекеево, радует песнями своих земляков. И сейчас зрители были ей благодарны, многие подпевали талантливой певице.



Вообще, такие концерты асекеевцев отличаются одной особенностью: в подавляющем большинстве своем на сцене молодые люди — парни и девушки — и даже совсем юные, как, например, Рим Кашапов. И каждое выступление профессиональнее, чем предыдущее. Молодые таланты хорошо держатся на сцене и практически не отличаются от именитых артистов.

Асекеевский зритель «избалован» такими выступлениями местных артистов. А ведь в некоторых других районах о таких концертах могут только мечтать.



**На снимках:** на сцене талантливая молодежь.

ТРАДИЦИИ

# И много, много радости детишкам принесла...




Накануне нового года, на электронный ящик редакции пришло письмо от какого-то возмущенного «исламского деятеля», который требует, чтобы татары, как этнические мусульмане, не праздновали Новый год, а елку в доме вообще считали бы признаком поклонения христианству. Никто не спорит, что украшение елки было «изобретено» христианами, как символ жизни и процветания. Но в России, это вечнозеленое дерево, скорее не религиозный символ, а дань традиции. Католики, православные отмечают Рождество, мы же, украшая елку, встречаем Новый год, и этот обычай давно превратился в светский праздник.

Для многих из нас елка дорога как память о детстве. В советские времена, мы и не знали толком, что такое Рождество. А вот на Новый год, в детских садах и школах, а у многих и дома, зажигали огни гирлянд елки. И это было символом новогодних чудес и ожиданий.

Помню, в школе военрук наряжался в Деда Мороза, а самая красивая старшеклассница становилась Снегурочкой. Скромные карамельки в мешке и счастливые глаза ребят. А скоро зимние каникулы! Разве это не чудо?!

Отец заносил елку с улицы и она сначала «плакала». Потом, дом заполнялся неповторимым запахом ели. Из запылившейся за год коробки доставались игрушки, и самая красивая водружалась на макушку дерева. Для детей нашего поколения это был настоящий праздник и стоит ли лишать своих детей и внуков этого чуда, в угоду сомнительным религиозным идеологам.

**На снимке:** самая главная елка села Асекеево.

**Ф.ГАЯЗОВ.**

ПОДВОДЯ ИТОГИ

# О ЧЕМ ПИСАЛА НАША ГАЗЕТА В 2009 ГОДУ

**Начался новый 2010 год — второй год существования нашей газеты. Теперь читатели имеют возможность подписаться на наше издание. В период становления газеты было опубликовано очень много интересных материалов. Жаль, что с ними могли ознакомиться не все наши читатели. Чтобы они имели представление об этих публикациях, мы подготовили краткий обзор наиболее интересных.**

В первом номере газеты за январь 2009 года рассказывалось о музее татарской культуры в Бугуруслане. «Богырыслан шәһәрендә, татарлар күмәкләшеп яшәгән җирдә икенче санны урта мәктәп балаларга яңа бинада үзенең ишекләрен ачты. Татар краенда урнашкан тагы ике мәктәп аның филиаллары булып калдылар. Бу уку йортларында байтак татар балалары белем алалар... Мәктәпнең беренче һәм өченче корпусында музейлар урнашты, анда татар халкының милли киемнәре, көнкүренештә куллана торган әйберләре белән балаларны таныштырабыз. Элек татарлар өендә хуҗаларга өстәл һәм карават урынына сәке булган.Шундый бер татар өенең почмагын икенче мәктәпнең музеенда (Победная урамында) күрергә мөмкин». Автор публикации Марат Закиров.

В нескольких номерах газеты публиковались отрывки из книги Марата Закирова о истории Бугуруслана. «...19-нчы гасырның азагында һәм 20-нче гасырның башында Богырыслан сәүдәгәрчеләр шәһәренә Идел буе тирәсеннән татарлар күчеп килгәннәр. Алар күбесе приказчиклар булып эшләгәннәр, кайсысы кондитер эшләнмәләре әзерләп, үзләренең кечкенә кибетләрендә сатканнар. Корьән кушуы буенча, ел саен мәчеткә, ятимнәргә диеп зәкят биргәннәр. Шәһәрдә ул вакытта ике мәчет булган. Берсе — Мещанская урамында, икенчесе — Нацменская урамында. Халык аларны түбәләренең буяуы өчен «кызыл» һәм «ак» мәчетләр дип йөрткәннәр...»

Во втором номере газеты под заголовком «Живое творчество народа.» рассказывалось о книге «Из истории Оренбургского государственного татарского театра». В этом театре в свое время служили и наши земляки. «Супруги Валишины прививали любовь к театру, к татарской культуре, песням танцам уже здесь, в Асекеево. Наиль Валишин написал несколько пьес и поставил как режиссер множество спектаклей на Асекеевской сцене... Есть в книге еще знакомые лица. Фания Зариповна Яхина родилась в Тюмени в семье военнослужащего. «Отец погиб на фронте, они с матерью переехали в село Асекеево. Там она окончила десять классов и участвовала в кружке самодеятельности в районном доме культуры. В 1957 году она была принята в Оренбургский татарский драматический коллектив филармонии. Проработав в театре более 20 лет, она создала ряд интересных музыкальных образов... За свой труд Ф.З Яхина неоднократно была награждена почетными грамотами облисполкома, управления культуры и филармонии. В настоящее время на заслуженном отдыхе, проживает в Асекеево»

В номере газеты за март был опубликован репортаж о межрегиональном фестивале татарской культуры «Ак хисләр». «...Дуртенче мартта Әсәкәй район мәдәният йортында быел төбәкара «Ак хисләр» фестивале үтте. Алты район һәвәскәрләре үзләренең осталыгын җырда, биюдә, фольклор, нәфис сүз жанрларында күрсәтteләр. «Ак хисләр» фестивалены «Гран-При» бүләгенә вокал жанрында Иске Мөъмин авылы Әсәкәй районы егете Радик Ганиевны лаек дип жюри карар чыгарды. Ул тәсле телевизор белән бүләкләнде. Беренче дәрәҗәле дипломга җырчы Аделя Юнусова Северный районнан лаек булды — кухонный комбайн белән бүләкләнде. Фольклор жанрында Яңа Солтангол авылы балалар бакчасының фольклор ансамбле «Каргатуй» исемле чыгышы өчен беренче дәрәҗә дипломга лаек булып кыйммәтле бүләк алды. Башка район һәвәскәр артистлары икенче, өченче дәрәҗәле дипломнар һәм бүләкләр алдылар. Самара әлкәсе Гали авылыннан; Абдулино районы Якуп авылыннан; Пономаревка районы Нуруз, Дусмәт авылларыннан; Северный районы Бакай авылыннан; Богырыслан шәһәреннән килгән һәвәскәрләр барысы да төрле жанрларда чыгыш ясап «Ак хисләр» фестиваленең истәлекле бүләкләрен һәм грамоталарын алып киттеләр. Фестивальнең биш еллыгын 100 дән артык һәвәскәр артистлар Наиля Фатехова башкаруында Нәзифа Каримова шигырено кушылып җырлап тәмамладылар».

В том же номере сообщается о создании Асоосиации. «Знаменательное событие произошло 13 марта 2009 года в Бугуруслане. В Доме культуры имени Г. Тукая, состоялось подписание Декларации, о создании межрегиональной Ассоциации татарских национально-культурных объединений «Бердәмлек». Пока, в Ассоциацию вошли три объединения: из Асекеева, Бугуруслана и села Алькино Самарской области. Но, здесь будут рады принять в свои ряды и других».

В четвертом номере газеты уже рассказывается о делах Ассоциации. «Бердәмлек» ассоциясенең беренче «карлыгачы» булып халкыбызның мәңгелек нуры булган Тукаебыз әсәрләреннән торган төбәкара конкурс Самара өлкәсендә Гали авылында булды. Конкурс номинацияләре: нәфис сүз, рәсем, җыр, бөек шагыйребез тормышына багышлаган сочинение. Самара өлкәсе авыллары һәм безнең Әсәкәй районы Яңа Солтангол һәм Тамьян авылларыннан балалар катнашты. Тукай мирасын беренче класстан алып 11 класс укучылары Гали авылы мәдәният йорты сәхнәсендә зур осталык белән сөйләделәр. Балаларның чын күңелдән туган телебезне шагыйрьнең тирән мәгънәле әсәрләре аша яңгыратуы залда утырган тамашачыларның күңелен әсир итте. Жюри һәрбер номинация буенча беренче, икенче һәм өченче дәрәҗә дипломнары билгеләде. Жюри рәисе Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе шайгыйрә Резеда Вәлиева конкурсантларны котлап дипломнар һәм бүләкләр тапшырды. Беренче дәрәҗә дипломантлары аның «Күңелем гөлләре» дигән шигырьләр китабы белән бүләкләнде».

В майском номере газеты мы писали о большом совете татар. «... 22 апрельда Әсәкәй район милли-мәдәни мөхтәрияте татар теле һәм мәдәнияте проблемаларына багышланган киң җәмәгатьчелек каршында киңәшмә уздырды. Бу киңәшмәгә җирле хакимият башлыклары, укытучылар, мәдәният хезмәткәрләре, мәктәп укучылары, хезмәт ветераннары чакырылган иде. Резеда апаның урыны бу киңәшмәдә президиум өстәле артында булды. Киңәшмәдә Әсәкәй район башлыгы Николай Макаров та катнашты. Район милли-мәдәни мөхтәрияте башлыгы Илдус Давлятов чыгышыннан соң укытучылар, мәдәният хезмәткәрләре туган телне һәм татар мәдәнияten үстерүдә алда торган проблемаларны төрле яклап сүрәтләделәр.Соңыннан район башлыгы чыгыш ясады. Ә Резеда апаның туган телебезгә татар мәдәниятенә карата булган мәгънәле чыгышы һәм аның ахырын шигырь юллары белән тәмамлауы залда утыручыларны сокландырды да уйландырды. Туган телгә карата гаиләдә хөрмәт тәрбияләргә кирәк, горефгадәтләребезне онытмаска, татар мәдәниятен алга таба үстерергә кирәк дигән сүзләр тыңлаучыларның хисләрен уятып тирән уйларга чумдырды».

Июнь — время сабантуя. «Гвоздевыми» материалами этого номера стали репортажи об открытии татарского подворья в Национальной Деревне в Оренбурге и о проведении сабатуя в Асекеевском районе. «И вот, ровно в одиннадцать, глава администрации Асекеевского района Николай Макаров объявляет сабантуй открытым. Гостям, среди которых были представители Татарстана — народный артист РТ Фердинанд Саляхов и представитель Всемирного конгресса татар Гульназ Шайхи, вручили хлеб соль. Гульназ Шайхи огласила приветствие президента Татарстана Минтимера Шаймиева. Прозвучали слова: «Татарстан халкы һәм шәхсән үз исемемнән сезнең барыгызны да чын йөрәктән сәламлим һәм Сабатуй милли бәйрәме белән тәбрик итәм!».





В июльском номере мы продолжили рассказы о сабантуях в районах области.

В августе одним из интересных материалов стал репортаж об уборке урожая в ОАО «Алга».

В сентябре рассказали о том, как мусульмане отмечают месяц Рамазан. «...И вот, и стар, и млад выстраиваются на праздничную молитву. Она короткая, но имеет огромную объединяющую силу. Затем идет праздничная проповедь -хутба в котором раскрывается величие Всевышнего...».

В октябре рассказали о фестивале «Алтын көз». Большой фоторепортаж был посвящен селу Чеганлы Абдулинского района. «...Больше всего меня поразил детский сад. За годы экономической разрухи многие дошкольные учреждения в стране позакрывались, и их здания встречают путника пустыми глазницами разбитых окон. Здесь же детский сад не прекращал работу. Более того, недавно проведен ремонт. Внутри тепло, уютно. Веселый гомон малышей. Причем, их не двати, а целая группа. Значит много в селе молодых семей...».

В ноябре мы писали о мастер классе Венера Хамитова — главного балетмейстера казанского театра юного зрителя города Казани. «Известный в Казани танцор Венер Хамитов вновь показал сельским ребятам, что такое танец. Как посредством движения, пластики показать поэзию песни без слов...».

В декабре мы писали о конкурсе «Мин бит татар баласы».

Конечно это не полный перечень опубликованных материалов. Ну а впереди читателей ожидают новые интересные публикации.

У нашей газеты солидный архив фотоматериалов. Не все снимки попали в газету. Просто, не поместились. Вот снимки из архива.

# ТЕКСТЫ ПОПУЛЯРНЫХ ТАТАРСКИХ ПЕСЕН



## Күбәләк

Күбәләк гөлләргә кунса,
Гөлләр тибрәнә микән?
Ул да мине сагынганда,
Күбәләгем, түгәрәгем,
Асыл кошым, сандугачым,
Җырлап җибәрә микән?

Күбәләккәй гөлгә кунган,
Гөлдә булгач оясы;
Минем күңелем сиңа тарта,
Күбәләгем, түгәрәгем,
Асыл кошым, сандугачым,
Син бит күңелем кояшы.

Тау астында, тал астында
Салкын чишмә түгәрәк;
Очып барып кайтыр идем,
Күбәләгем, түгәрәгем,
Асыл кошым, сандугачым,
Әгәр булсам күбәләк.

## Зәңгәр күлмәк

Зәңгәр күлмәгеңне киясең дә,
Зәңгәр күлгә көн дә килäсең.
Йөрәгеңдә нинди утлар яна?
— Уйларыңны килә беләсем.

Зәңгәр күлмәгеңне киясең дә,
Яшел болыннардан үтәсең.
Болын чәчәкләрен җыя-җыя,
Кемне болай сагынып көтәсең?

Зәңгәр күлмәгеңнең зәңгәрлеге
Хәтерләтә аяз күкләрне.
Нинди иркә сүзләр ачар икән
Күңелеңнең серле бикләрен?!

## Ай былбылым

Ай былбылым, вай былбылым,
Агыйделнең камышы;
Таң алдыннан чут-чут килә
Сандугачлар тавышы.

Ай былбылым, вай былбылым,
Агыйделдә таң ата;
Таңнар ата, өзелә үзәк,
Җырлата да елата.

Ай былбылым, вай былбылым,
Кунып сайрый талларга;
Синең хакта серләремне
Сөйлим сандугачларга.

## Туй җыры

Икәү бергә утыргансыз,
Бергә булсын уегыз;
Икегез дә пар килгәнсез,
Котлы булсын туегыз!

Пар былбыллар кавышкандай,
Ничек кавыштыгыз сез?!
Бу кадәр матур пар булып
Ничек табыштыгыз сез?!

Сокланып карап туймассың
Зифа буегызга да.
Онытмагыз чакырырга
Бәбәй туегызга да.



# ТАТАР ХАЛЫК АШЛАРЫ

Чумарлы ашка бәрәңге һәм кишер салырга мөмкин. Ул чагында чумарны бәрәңге пешкәч салырга кирәк.

Чумарны бодай, борчак, карабодай һәм ясмык онынннан да тугларга мөмкин.

35-40 гю он, 1,5 –йомырка, 30-40 г. су яисә шулпа, кирәгенчә тоз, борыч.

## Чумар (кашык чумары)

Сарык, сыер яисә тавык итеннән шулпа әзерлиләр. Итне алгач, шулпасын сөзәләр дә шулпанын беразын камыр өчен суыталар, калганы белән аш пешерәләр.Чумар ясау өчен, савытка он иләп салалар, уртасын чокырлыйлар, йомырка сытып, тоз сипкәч, аз-азлап шулпа салып камыр изәләр. Шулпа җылымса гына, йомырка пешмәслек булырга тиеш. Камырны йомшак (куе каймак кебек) , шулай да кашыктан агып төшмәслек һәм төерләр калмаслык итеп яхшылап туглыйлар.

Әзерләгән камырдан балкашык белән урман чикләвеге кадәр алып кайнап торган шулпага яисә ашка салалар.

Чумар башта төпкә бата, аннары өскә күтәрелә, бераздан пешеп җитә.

## Умач

Умачны бик тиз әзерләп була. Аны бодай, арыш, борчак, карабодай, солы онынннан уалар. Аның белән итле, сөтле һәм кысыр ашлар пешерәләр.

Умач уу өчен, савытка иләгән он салып, уртасын чокырлыйлар, аннары аз-азлап тозлы шулпа яисә су (шулпа яисә су токмач һәм чумар камырына караганда кимрәк салына) өсти торып, яхшылап болгаталар һәм борчактан зуррак вак кына төерләр барлыкка килгәнче он белән уалар. Әзер умачны, оешмасын өчен, кайнап торган шулпага ике кул белән уыштырып салалар һәм болгатып торалар. Умач өскә калыккач, ашны тагын 2-3 минут кайнаталар.

35-40 г. он, 30-35 г. шулпа яисә су, кирәгенчә тоз.



# НАМАЗ ВАКЫТЛАРЫ

(время местное)

| ФЕВРАЛЬ | Фаджр Иртә | Восход Кояш чыга | Зухр Өйлә | Аср Икенде | Магриб Ахшам | Иша Ясту |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 8-17 | 9-17 | 14-10 | 16-16 | 18-16 | 19-46 |
| 2 | 8-15 | 9-15 | 14-10 | 16-18 | 18-18 | 19-48 |
| 3 | 8-13 | 9-13 | 14-10 | 16-20 | 18-20 | 19-50 |
| 4 | 8-11 | 9-11 | 14-10 | 16-22 | 18-22 | 19-52 |
| 5 | 8-09 | 9-09 | 14-10 | 16-24 | 18-24 | 19-54 |
| 6 | 8-08 | 9-08 | 14-10 | 16-26 | 18-26 | 19-56 |
| 7 | 8-06 | 9-06 | 14-10 | 16-28 | 18-28 | 19-58 |
| 8 | 8-04 | 9-04 | 14-10 | 16-30 | 18-30 | 20-00 |
| 9 | 8-00 | 9-02 | 14-10 | 16-32 | 18-32 | 20-02 |
| 10 | 7-58 | 9-00 | 14-10 | 16-34 | 18-34 | 20-04 |
| 11 | 7-56 | 8-58 | 14-10 | 16-36 | 18-36 | 20-06 |
| 12 | 7-54 | 8-56 | 14-10 | 16-38 | 18-38 | 20-08 |
| 13 | 7-52 | 8-54 | 14-10 | 16-40 | 18-40 | 20-10 |
| 14 | 7-50 | 8-52 | 14-10 | 16-42 | 18-42 | 20-12 |
| 15 | 7-48 | 8-50 | 14-10 | 16-44 | 18-44 | 20-14 |
| 16 | 7-46 | 8-48 | 14-10 | 16-46 | 18-46 | 20-16 |
| 17 | 7-44 | 8-46 | 14-10 | 16-48 | 18-48 | 20-18 |
| 18 | 7-42 | 8-44 | 14-10 | 16-50 | 18-50 | 20-20 |
| 19 | 7-39 | 8-42 | 14-10 | 16-52 | 18-52 | 20-22 |
| 20 | 7-37 | 8-39 | 14-10 | 16-54 | 18-54 | 20-24 |
| 21 | 7-35 | 8-37 | 14-10 | 16-56 | 18-56 | 20-26 |
| 22 | 7-33 | 8-35 | 14-10 | 16-58 | 18-58 | 20-28 |
| 23 | 7-31 | 8-33 | 14-10 | 17-00 | 19-00 | 20-30 |
| 24 | 7-28 | 8-31 | 14-10 | 17-02 | 19-02 | 20-32 |
| 25 | 7-26 | 8-28 | 14-10 | 17-04 | 19-04 | 20-34 |
| 26 | 7-24 | 8-26 | 14-10 | 17-06 | 19-06 | 20-36 |
| 27 | 7-22 | 8-24 | 14-10 | 17-08 | 19-08 | 20-38 |
| 28 | 7-21 | 8-22 | 14-10 | 17-10 | 19-10 | 20-40 |

**Данные предоставлены Бугурусланским муфтиятом.**
**Возможна разница во времени в сравнении с другими источниками, на 3-5 минут.**

# ПРОГНОЗ ПОГОДЫ

## (Бугуруслан)

| ЯНВАРЬ | ДНЕМ | НОЧЬЮ |
|---|---|---|
| 13 | -14°. | -17°. |
| 14 | -20°. | -23°. |
| 15 | -22°. | -28°. |
| 16 | -18°. | -18°. |
| 17 | -19°. | -21°. |
| 18 | -21°. | -22°. |
| 19 | -19°. | -23°. |
| 20 | -19°. | -24°. |
| 21 | -19°. | -19°. |
| 22 | -19°. | -19°. |
| 23 | -19°. | -19°. |

**www.gismeteo.ru**

# ОБЪЯВЛЕНИЕ



Редакция газеты «Туган як. Родной край» принимает для публикации **поздравления и благодарности** на татарском языке, адресованные вашим родным и близким, в том числе и в стихотворной форме. **Стоимость 100 рублей.**

Так как газета выходит два раза в месяц, надо позаботиться о поздравлениях заблаговременно.

Так же, принимаем **обычные объявления**. **Стоимость 150 рублей.**

ТУГАН ЯК РОДНОЙ КРАЙ

**E-MAIL:** tugan-iak-asekeevo@yandex.ru

**УЧРЕДИТЕЛЬ:**
ТАТАРСКАЯ НАЦИОНАЛЬНО КУЛЬТУРНАЯ АВТОНОМИЯ
**АДРЕС РЕДАКЦИИ:**
С.АСЕКЕЕВО, УЛ.ЧАПАЕВА 24.
**ТЕЛЕФОН:** (353-51) 2-22-81

Распространяется в Асекеевском, Абдулинском, Бугурусланском, Матвеевском, Пономаревском, Северном районах. Свидетельство о регистрации ПИ №ТУ 56-00065, выданное Управлением Федеральной службы по надзору в сфере связи и массовых коммуникаций по Оренбургской области.

ГАЗЕТА ОТПЕЧАТАНА
В БУГУРУСЛАНСКОЙ ТИПОГРАФИИ.
461600, г.Бугуруслан,
ул.Революционная, 14.
Цена свободная. ТИРАЖ: 2000 ЭКЗ.

**Главный редактор: Фарит НУГУМАНОВ**